| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 нчы ноябрь, 2024 ел Багай ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Багай авыл җирлегенең Араслан авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсә , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 маддәсә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябренә 10 сәгать 00 минутка , Араслан авылы , Кооператор урамы, 20а йорт адресы буенча урнашкан кибет янында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегең Араслан торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләрг

2. 2024 елның 20 ноябренә 13 сәгать 30 минутка, Араслан клубы бинасында: Араслан авылы, Чапаев урамы, 18 йорт, адресы буенча урнашкан , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Араслан торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Багай авыл җирлеге Араслан торак пункт территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер СИП чыбыклары сатып алу) ;

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау ,төзү һәм ремонтлау ;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән территорияне )

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларнын төзү,каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?”

« РИЗА» «КАРШЫ»

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Республикасы Кайбыч муниципаль районының**
**Багай авыл җирлеге Башлыгы** Кузнецова **Р.Ф.Кузнецова**